**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Базарлы Матак** **КАРАР**

2023 елның 22 марты 72№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 декабрендәге «Әлки муниципаль районының муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 527 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге "2022 елда субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү һәм күрсәтелгән субсидияләрне һәм субсидияләрне федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бирү үзенчәлекләре турында" 590 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районының муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.8.Эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле вәкаләтле органы субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерә, шулай ук муниципаль финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә;";

2. 2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми http://pravo.tatarstan.ru порталы"нда һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.Н.Балакирев